# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2025 елда Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең Сеитово торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында

2024 елның 02 декабреннән №02

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Сеитово торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең Сеитово торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, мобилизацияләнгән гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан һәм күп балалы гаиләләрдән тыш, һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 1000 сум күләмендә кертергә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Сеитово торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Макыл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Югары Ослан муниципаль районы
Макыл авыл җирлеге башлыгы П.Е.Карпухин